# SAFIULLINA FLORA SADRIEVNA

**Alfiya ShavketovnaYusupova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation.
alyusupova@yandex.ru.

**Elvira Nikolaevna Denmukhametova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation.
elvir25@mail.ru.



**FLEIRA SADRIYEVNA SAFIULLINA** (1938–2011) was a researcher, a linguist, Doctor of Philology (2000), Professor of Kazan State University (now KFU) (1997), Head of the Department of Applied Linguistics and Translation Studies (1992–2008). Prof. Safiullina was Honored Teacher of the Republic of Tatarstan (1993), a laureate of the Kayum Nasiry Award of 2001, a full member of International Turkish Academy (1997), and Honored Researcher of the Republic of Tatarstan (2004).

**ФЛЁРА САДРЫЙ КЫЗЫ САФИУЛЛИНА** (1938–2011) – галимә, татар теле белгече, филология фәннәре докторы (2000), Казан дәүләт университеты (хәзер КФУ) профессоры (1997), гамәли тел белеме һәм тәрҗемәчелек кафедрасы мөдире (1992–2008). Татарстанның атказанган укытучысы (1993), Каюм Насыйри премиясе лауреаты (2001), Халыкара төрки академиянең хакыйкый әгъзасы (1997), Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (2004).

**ФЛЕРА САДРИЕВНА САФИУЛЛИНА** (1938–2011) – ученый, лингвист, доктор филологических наук (2000), профессор Казанского государственного университета (ныне КФУ) (1997), зав. кафедрой прикладной лингвистики и переводоведения (1992–2008). Заслуженный учитель РТ (1993), лауреат премии Каюма Насыри (2001), действительный член Международной турецкой академии (1997), Заслуженный деятель науки РТ (2004).

Safiullina Flora Sadrievna was born into the family of office workers on May 24, 1938, in the village of Tlyanchi-Tamak, the Voroshilovsky (now Tukaevsky) district of TASSR. In 1945-1953, F. S. Safiullina went to the Tlanchi-Tamak secondary school. In 1953, the Safiullins moved to the Novo-Churilinsky district and she continued her studies at the local school. After leaving the Novo-Churilinskaya secondary school of Tatarstan in 1955, she entered the Department of the Tatar Language and Literature, the School of History and Philology in Kazan State University. In 1960, she graduated from the University with honors.

In 1960, F. S. Safiullina began her career as a laboratory assistant in the Department of the Tatar Language, later she became a lecturer in the same Department. In 1962-1965, she took a postgraduate course at the Department and, in 1966, she presented her thesis on “The Order of Words in the Modern Tatar Literary Language” written under Professor M. Z. Zakiev’s supervision. Until 1971,

she was an assistant professor in the same Department, later she became an associate professor.

When, in March 1992, a new Department of Tatar as a Non-native Language was opened, F. S. Safiullina became its first Head. At that time, it was the only department of this type not only in Tatarstan, but also in Russia. F. S. Safiullina held this position until 2008.

From the very first days of its work, the department, headed by F. S. Safiullina, worked fruitfully to develop and publish textbooks, educational aids for teaching the Tatar language, and compiled various dictionaries. The members of the Department were engaged in drafting curricula for teaching the Tatar language to Russian-speaking students at schools and universities of the Republic of Tatarstan. The Department became the Center for teaching the Tatar language to foreign students and interns from different countries of the world (England, the USA, Germany, Taiwan, China, Japan, etc.).

Even before F. S. Safiullina presented her doctoral thesis in 1997, she had been granted the academic title of professor. In 2000, Prof. Safiullina successfully defended her thesis for the degree of Doctor of Philology in the form of a scientific report on “The Development of the Syntactic Structure of the Tatar Literary Language (the twentieth century)”. The thesis was highly appreciated by such well-known scientists-turkologists, as E. R. Tenishev, M. Z. Zakiyev, I. A. Andreev, R. Sibagatov and others.

F. S. Safiullina’s scientific activity is distinguished by a wide range of research issues in the area of Tatar linguistics: syntax, lexicology, lexicography, and linguomethodology. She is the author and co-author of more than 500 publications, among them are 100 monographs, textbooks for universities and schools, various dictionaries, as well as scientific and scientific-methodological articles.

In Tatar linguistics and turkology, F. S. Safiullina was the first to study the syntax of the Tatar spoken language, dialect syntax and text style, comparative syntax of the Russian and Tatar languages. Flora Sadrievna’s scientific research chronologically covers the whole century – the entire twentieth century. This is a very complex and contradictory period of the Tatar literary language development. The turbulent events of the 20th century - the democratic revolution of 1905, the October Revolution of 1917 and the subsequent general political processes, the years of Stalinist repression, the thaw of the 1960s, the perestroika and post-perestroika times, and finally, the democratization that began in the 1980s, had a decisive influence on the nature of the literary language development. Against this background, the scientist identifies extralinguistic conditions, directly influencing the renewal and improvement of language structures: the general literacy of the population, the further development of book printing, the expansion of the mass media network (newspapers, radio, television), the spread of colloquial forms of the literary language in scientific and public speech, the development of ethnic-Russian bilingualism, etc.

F. S. Safiullina managed to highlight such interesting phenomena of the Tatar syntax as truncated constructions, parcellation, initiation, chain sentences, actual division, “colloquial” constructions, etc. Dialectological materials, personally collected by the scientist, enabled her to clearly demonstrate the influence of colloquial and dialect speech on literary language. Having studied a great number of literary texts from different periods, F. S. Safiullina was able to trace the influence of a fictional word, characterized by stylistic diversity, on the norms of other functional styles of the Tatar language. When analyzing the dynamics of the syntactic system, F. S. Safiullina rightly notes that many innovations were a natural development and activation of certain features of the Turkic syntax that are historically inherent in it. However, this development is stimulated both by internal and external factors of the language, in particular, by mass ethnic-Russian bilingualism. In different periods of her scientific career, the scholar devoted dozens of articles to the research into these processes.

For over 40 years, F. Safiullina lectured on Foundations of Linguistics, Modern Tatar (Phonetics, Lexicology, Syntax), Methodology of Teaching Tatar as a Foreign Language, and Syntactic Structure of the Tatar Language. She wrote a number of textbooks and educational materials for tertiary level, constantly updating her special courses. It was due to F. S. Safiullina’s organizational and scientific talent, that the Tatar language has been taught to Russian-speaking students of all faculties in KFU.

F. S. Safiullina is the founder of the linguistic methodology for teaching Tatar as a foreign language. She is the author of numerous works on teaching the Tatar language. Among her works are textbooks for schoolchildren and for students, self-study books and educational materials for those who want to learn the Tatar language.

F. S. Safiullina compiled over ten dictionaries.

Prof. Safiullina managed to establish her own research school on studying the Tatar literary language and teaching Tatar as a foreign language. She was the research supervisor of post-graduate students and young scientists. She supervised a doctoral dissertation (A. Sh. Yusupova) and over 15 candidate dissertations (A. Sh. Yusupova, L. M. Rizvanova, I. G. Miftakhova, Z. N. Kirillova, G. A. Nabiullina, R. Kh. Mukhiyarova, E. N. Fedorova, G. R. Mugtasimova, B. E. Hakimov, R. S. Nurmukhametova, L. G. Gilyazova, F. R. Sibgaeva, L. A. Yansaeva, G. M. Shavalieva, M. R. Shaehov, and others). F. S. Safiullina's disciples are conducting active scientific, pedagogical and methodological activities in various educational institutions of the country, keeping the traditions of their teacher.

During her career, F. Safiullina eagerly shared her professional and research experience. She presided at international, regional and republican scientific and practical conferences on the topical issues of Turkic Studies, Linguistics, Linguistic Didactics, participating in symposiums and forums in Istanbul, Moscow, Baku, Tashkent, Almaty, Samarkand, Kazan, Ufa, Cheboksary, etc.

Three times F. S. Safiullina was awarded the title of a laureate of Kazan State University for best monographs ("The Order of Words in the Tatar Language" (1974), "The Tatar Language: A Self-Study Book" (1990), "The Development of the Syntactic Structure of the Tatar Language in the Soviet Period" (1992)).

In recognition of great achievements in the development of Tatar linguistics and fruitful research activity, F. S. Safiullina was elected a full member of the International Turkic Academy (1997). She was awarded the Certificate of Honor of the Republic of Tatarstan for her great services in preparation of scientific and pedagogical personnel, her active methodological and public activities (1998); she was awarded the honorary title "Honored Teacher of the Republic of Tatarstan" (1993). She was an "Honored Teacher of Kazan University" (2008). In 2000, F. S. Safiullina became the Woman of the Year 2000 in the Republic of Tatarstan in the nomination "Patience and Labor to Glory Are Leading". In 2001, she was awarded the Kayum Nasyri Prize for the development of teaching aids and original scientific research in the field of national education. She was the third woman who wore the "silver bracelet" of the magazine "Syuyumbike" (2001). In 2004, she was awarded the honorary title "Honored Worker of Science of the Republic of Tatarstan".

F. S. Safiullina actively participated in the public life of the Faculty of Tatar Philology and History of KSU. She was a member of the Academic Council of the Faculty, a member of the State Commission for the Implementation of the Tatar Language in the Republic of Tatarstan, a member of the editorial board of the republican magazines "Yalkin", "Magarif", and "Syuyumbike".

F. S. Safiullina deceased on December 6, 2011, after an extended illness. She was buried in Old-Tatar Cemetery in Kazan.

**References**

*Fəngə bagyshlangan gomer = Zhizn', posvyashchonnaya nauke* (2008) [Life Dedicated to Science]. Təz. F. R. Sibgayeva; məy. Ə. Sh. Yusupova. 214 p. Kazan, Kazan dəүlət universitety nəshriyaty. (In Tatar)

*Kazan universitetynda iarty gasyr... (Kazan universitety galime professor F. S. Safiullinanyң iakty istəlegenə bagyshlana)* (2013) [Half a Century at Kazan University... Dedicated to the Bright Memory of Kazan University Professor F. S. Safiullina]. 220 p. Kazan, Ikhlas. (In Tatar)

*Tatar entsiklopedia syzlege* (2002) [Tatar Encyclopedia Dictionary]. P. 548. Kazan. (In Tatar)

# САФИУЛЛИНА ФЛЁРА САДРИЕВНА

**Әлфия Шәүкәт кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
alyusupova@yandex.ru.

**Эльвира Николай кызы Денмөхәммәтова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
elvir25@mail.ru.

Флёра Садрый кызы Сафиуллина 1938 нче елның 24 нче маенда ТАССРның элеккеге Сарман (хәзерге Тукай районы) Теләнче Тамак авылында хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә. Башта туган авылында сигезьеллык мәктәптә укый. 1953 нче елда, әтисе Яңа Чүриле районына (хәзерге Арча районы) эшкә җибәрелү сәбәпле, гаиләләре белән шул районга күчеп китәләр һәм ул укуын шунда дәвам итә. Ф. С. Сафиуллина, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетына – тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1960 нчы елда бүлекне кызыл диплом белән тәмамлый.

Ф. С. Сафиуллина хезмәт эшчәнлеген 1960 нчы елда университетның татар теле кафедрасында лаборант буларак башлап җибәрә, аннары яңа оешкан татар теле кафедрасында ассистент вазифасын башкара. Күренекле галим М.З. Зәкиев җитәкчелегендә 1962–1965 нче елларда аспирантура үтеп, 1966 нчы елда «Татар телендә сүз тәртибе» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Флёра Садриевна 1971 нче елга кадәр әлеге кафедрада ассистент, соңрак доцент булып эшли.

Ф. С. Сафиуллинаның эшчәнлеге алга таба да Казан университеты белән бәйле була. 1992 нче елның мартында Казан дәүләт университетында Татарстанда гына түгел, ә бөтен Россиядә әле бердәнбер булган татар теленә өйрәтү кафедрасы ачыла. Галимә аның беренче җитәкчесе итеп билгеләнә һәм ул бу вазифаны 2008 нче елгача башкара.

Кафедрада, ачылган көненнән башлап, Ф. С. Сафиуллина җитәкчелегендә татар теленә өйрәтү өчен дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары, төрле сүзлекләр төзү эше җәелдерелә. Кафедра хезмәткәрләре, рус телле укучыларга татар телен өйрәтү юнәлешендә, Татарстан Республикасы мәктәпләре һәм югары уку йортлары өчен программалар төзиләр, бу юнәлештә фәнни-методик ярдәм күрсәтәләр. Кафедра чит ил студентлары һәм стажерларына татар телен өйрәтү үзәгенә дә әверелә. Анда Англия, АКШ, Германия, Тайвань, Кытай, Япония һ. б. илләрдән килгән студентлар татар телен үзләштерәләр. Ф. С. Сафиуллина республикабызда татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кертүгә зур хезмәт куя. Галимә җитәкчелегендә чит ил һәм Россия университетлары белән фәнни-эзләнү элемтәсе булдырыла. Ул Берлинның Азат университетындагы (Германия) Тюркология институты белән хезмәттәшлек итә, Хельсинкида татар теле буенча лекцияләр укый.

Флёра Садриевна Сафиуллинага 1997 нче елда (докторлык диссертациясен яклаганчы ук) профессор дәрәҗәсе бирелә. Ә 2000 елда ул «Татар әдәби теле синтаксисының үсеше (XX гасыр)» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Аның күпьеллык фәнни хезмәте күренекле тюркологлар Э. Р.Тенишев, М. З. Зәкиев, И. А. Андреев, Р. Сибәгатовлар тарафыннан югары бәяләнә.

Профессор Ф. С. Сафиуллина – 300 дән артык фәнни монографияләр һәм фәнни-методик хезмәтләр авторы. Моннан кала, ул – 500 гә якын фәнни һәм укыту-методик мәкаләләре белән татар тел белеменең үсешенә зур өлеш керткән шәхес. Алар арасында татар теленең синтаксисы, лексикологиясе, стилистикасы, татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасы, югары уку йортлары, мәктәпләр, колледжлар, гимназияләр өчен программалар, дәреслекләр зур урын алып тора. Галимә лексикография (антонимнар, синонимнар, омонимнар, татар һәм рус фразеологик сүзлекләре, лингвистик әйтелмәләр сүзлеге, балалар өчен рәсемле сүзлек, татарча-русча, русча-татарча кесә сүзлеге һ. б.), татар телен чит тел буларак укыту методикасы юнәлешләрендә дә эшли.

Ф. С. Сафиуллина, татар һәм төрки тел белемендә беренчеләрдән булып, татар сөйләм

теле синтаксисын, диалекталь синтаксис һәм текст стилистикасы, рус һәм татар телләренең чагыштырма синтаксисларын өйрәнә. Аның фәнни тикшеренүләре хронологик яктан тулы бер дәверне – XX гасырны үз эченә ала. Бу – татар әдәби теле үсешендә бик катлаулы һәм каршылыклы чор. XX гасырның иҗтимагый-сәяси вакыйгалары – 1905 нче елгы инкыйлаб, 1917 нче елгы Октябрь борылышы, Сталин репрессияләре, 60 нчы еллардагы үзгәрешләр, үзгәртеп кору һәм аннан соңгы чор, 80 нче елларда башланып киткән сүз иреге һ.б.лар – барысы да әдәби тел үсешенә дә зур йогынты ясый. Галимә хаклы рәвештә әлеге вакыйгаларга бәйле төп экстралингвистик шартларны аерып чыгара һәм халыкның мәгърифәт дәрәҗәсе арту, китап бастыру эшенең дәвам итүе, массакүләм мәгълүмат чараларының күбәюе (газета чыгару эшчәнлеге җәелдерелү, радио һәм телевидение барлыкка килү) – барысы да әдәби телнең сөйләмә формасы фәнни һәм публицистик сөйләмдә таралу, милли-рус икетеллелеге үсеш алу һ.б.га этәргеч булуны ассызыклый.

Ф. С. Сафиуллина кыскартылма конструкцияләр, парцелляция, башлам, сөйләмнең актуаль кисәкләре, «сөйләмә конструкцияләр» һ. б. татар синтаксисында урын алган кызыклы күренешләрне бәян итә. Үзе туплаган тел материалларына таянып, ул сөйләм теле һәм диалектларның әдәби телгә тәэсирен дәлилләп күрсәтә. Галимә тарафыннан күп еллар дәвамында җыелган текст материаллары аңа әдәби сөйләмнең татар теленең төрле фукциональ стильләренә йогынты ясавын, алардагы үзгәрешләрне аңлатырга ярдәм итә. Синтаксик төзелеш динамикасын күзәтеп, Ф. С. Сафиуллина төрки синтаксиска хас күпчелек үзгәрешләрнең закончалыклы булуын раслый. Шул ук вакытта аларның телнең эчке һәм тышкы факторлары тарафыннан тизләтелүен дә кире какмый. Аерым алганда, киң таралыш алган милли-рус икетеллелегенең тәэсире зур булуын ассызыклый. Бу процессларны галимә төрле елларда язган дистәләгән фәнни мәкаләләрендә тасвирлый.

Ф. С. Сафиуллина 40 елдан артык «Тел белеменә кереш», «Хәзерге татар әдәби теле (фонетика, лексикология, синтаксис)», «Чит аудиториядә татар телен укыту методикасы», «Татар теленең синтаксик төзелеше» фәннәреннән югары уку йорты студентларына лекцияләр укый. Шул ук фәннәр буенча дәреслекләр, уку әсбаплары бастырып чыгара. Тел белемендә булган үзгәрешләргә бәйле рәвештә, ул махсус курс темаларын һәм аларның эчтәлеген даими яңартып тора. Ф. С. Сафиуллинаның оештыру сәләте һәм фәнни дәрәҗәсе нәтиҗәсендә Казан дәүләт университетының барлык факультетларында да рус телле студентларга татар теле фән буларак укытыла.

Ф. С. Сафиуллина – чит телле укучыларга татар телен өйрәтү методикасын булдыруга нигез салучыларның берсе. Ул – татар теленә өйрәтүгә багышланган күпсанлы фәнни хезмәтләрнең авторы. Алар арасында мәктәп укучылары, студентлар өчен язылган дәреслекләр дә, татар телен үзлектән үзләштерергә теләүчеләр өчен язылган үзөйрәткечләр һәм укыту-методик әсбаплар да бар.

Ф. С. Сафиуллина – дистәдән артык сүзлек авторы.

Флёра Садриевна – үзенең көчле фәнни мәктәбен булдырган галимә. Ул аспирантларның һәм яшь галимнәрнең фәнни җитәкчесе, остазы була. Аның җитәкчелегендә докторлык (Ә. Ш. Юсупова), дистәдән артык кандидатлык диссертацияләре (Ә. Ш. Юсупова, Л. М. Ризванова, И. Г. Мифтахова, З. Н. Кириллова, Г. Ә. Нәбиуллина, Р. Х. Мөхиярова, Э. Н. Федорова, Г. Р. Мөгътәсимова, Б. Э. Хәкимов, Р. С. Нурмөхәммәтова, Л. Г. Гыйләҗева, Ф. Р. Сибгаева, Л. А. Янсаева, Г. М. Шәвәлиева, М. Р. Шәехов һ. б.) якланды. Укучылары, остазларының эшен дәвам итеп, хәзерге вакытта илебезнең төрле белем бирү уку йортларында фәнни-педагогик һәм методик эшчәнлек алып баралар.

Эшчәнлеге дәвамында Ф. С. Сафиуллина эш тәҗрибәсе һәм фәнни яңалыклары белән бик теләп уртаклаша. Ул тел белеме, тюркологиянең актуаль мәсьәләләренә, лингводидактикага багышланган халыкара, төбәк һәм республика фәнни-гамәли конференцияләрендә чыгыш ясый, Истанбул, Мәскәү, Баку, Ташкент, Алматы, Сәмәрканд, Казан, Уфа, Чабаксар һ. б. шәһәрләрдә узган симпозиум һәм форумнарда актив катнаша.

Ф. С. Сафиуллина өч тапкыр Казан дәүләт университетының иң яхшы монография авторы («Татар телендә сүз тәртибе» (1974); «Татар теле. Үзөйрәткеч» (1990); «Татар теле синтаксисының Совет чорында үсеше» (1992) китаплары өчен) дәрәҗәсенә лаек була.

Татар тел белеме үсешенә керткән өлеше һәм нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге өчен, Ф.С. Сафиуллина 1997 нче елда Халыкара төрки

академиянең хакыйкый әгъзасы буларак сайлана. Фәнни һәм педагогик кадрлар әзерләүдәге зур казанышлары, актив методик һәм җәмәгать эшчәнлеге алып баруы өчен, ул 1998 нче елда Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Флёра Садриевна – «Татарстан Республикасының атказанган укытучысы» (1993), «Казан университетының атказанган мөгаллимәсе» (2008), «2000 нче ел Хатын-кызы» дигән дәрәҗәле исем һәм Каюм Насыйри исемендәге премия иясе (2001), «Сөембикә» журналының «көмеш беләзеген» йөртүче өченче хатын-кыз (2001). Ул 2004 нче елда «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исеменә лаек була.

Ф. С. Сафиуллина Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультеты тормышында актив катнашты. Ул факультетның гыйльми совет әгъзасы була. Шулай ук, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру комитеты әгъзасы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының укыту-методик Советы әгъзасы, «Сөембикә», «Ялкын», «Мәгариф» журналларының редколлегия әгъзасы иде.

Ф. С. Сафиуллина 2011 нче елның 6 нчы декабрендә озакка сузылган авырудан соң вафат булды. Ул Казан шәһәренең Иске татар бистәсе зиратына җирләнгән.

**Әдәбият**

Фәнгә багышланган гомер = Жизнь, посвящённая науке / [төз. Ф. Р. Сибгаева; мөх. Ә. Ш. Юсупова]. Казан: Казан дәүләт университеты нәшрияты, 2008. 214 б.

Казан университетында ярты гасыр... (Казан университеты галиме профессор Ф. С. Сафиуллинаның якты истәлегенә багышлана). Казан: Ихлас, 2013. 220 б.

Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2002. Б. 548.